Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Мамадыш муниципаль районының «Балалар һәм яшүсмерләр йорты»
өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе

Педагогик совет утырышында
кабул ителде «31» 08 2023 ел
Беркетмә № 1

Раслыйм:
«Балалар һәм яшүсмерләр йорты»
директоры
Ефимов А.М.
«31» 08 2023 г.

Сәнгать-эстетик юнәлешендәге
өстәмә гомуми белем бирү программасы
**“Халык авыз иҗаты”**
Укучыларның яше: 7-13 яшь (кече төркем)
Үтәлү вакыты: 3 ел


Автор-төзүче:
Ахмадиева Зоя Васильевна,
өстәмә белем бирү педагогы


Мамадыш, 2023 ел

1

# Эчтәлек


Аңлатма язуы……………………………………………………… ..... 3

Программаның максаты һәм бурычлары……………………..............3

Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре....... ..... 5

Беренче уку елына тематик план..........................................................6

Уку планының эчтәлеге…………………………………………….....6-7

Икенче уку елына тематик план…………..................................... ... 8

Уку планының эчтәлеге ……………………………………….. ..... 8-9

Учебный план третьего года обучения……………………………...10

Содержание учебного плана ……………………………………... ... 10-11

Методик, дидактик һәм матди-техник тәэмин ителү аша программаны тормышка ашыру ..........................................................................................12

Файдаланылган әдәбият исемлеге………………...................................13

**Аңлатма язуы**

Халык педагогикасы – тәрбия бирүдә халыкта яшәп килгән карашлар, тәрбияләү, укыту алымнары һәм чаралары, буыннан – буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәр, халык өйрәтүләре. Аның эчтәлегенә - фольклор әсәрләр, этнографик материаллар, халык традицияләре, уен һәм бәйрәмнәр, сәнгатьчә эшләнгән борынгы бизәнү әйберләре, традицион һөнәрләр, гаилә тәрбиясе тәҗрибәсе һ.б. керә.

Халык педагогика төшенчәсен педагогик әдәбиятка рус педагогы К.Д.Ушинский кертә. Ушинскийның педагогик системасы нигезендә халыкчанлык идеясы ята. Балаларда патриотизм, Ватанга мәхәббәт сыйфатлары халык тәрбиясендә характерлы үзенчәлек дип искәртә ул. Аның фикеренчә, туган тел халыкчанлыкның иң камил чагылышы булганлыктан, баланы укыту ана телендә булырга тиеш. Тел- халыкның үткән, хәзерге һәм киләчәк буыннарын тоташтыручы нык элемтә, халык теле юкка чыкса, халык та бетә, ди ул.

Кызганычка каршы бүгенге көндә байтак яшьләребез туган тел, ана теле дигән олуг нигъмәттән мәхрүм калып, ата-бабалары ишетмәгән ямьсез сүзләр үзләштерделәр. Милләтен оныткан, гореф-гадәтләреннән читләшкән яшьләр саны көннән-көн арта бара.Менә шуның өчен Язучы Нажар Нәҗми сүзләре белән әйтсәк:

Бер беребезгә нинди бәгырсез без,

Хәтта кансыз – кемнән өйрәндек?

Усаллыкка, әдәпсезлекләргә

Нинди иләк аша иләндек?

Ата-баба гомер юлымы бу –

Без нинди соң, нинди юл алдык?

Аерылдык җирдән, йолалардан,

Үзебездән үзебез югалдык.

**Программаның яңалыгы:** Балалар тәрбиялүдә фольклор әсәрләренең йогынтысы көчле. Ул акылны, зиһенне үстерә, хисләрне тәрбияли, намуслы, саф күңелле, кыю, тырыш һәм эшлекле булырга, кешелек дәрәҗәңне һәрвакыт югары тотарга өйрәтә. Халык педагогикасын өйрәнгәндә безгә турыдан туры татар халык авыз иҗаты чыганакларына мөрәҗәгать итәргә туры килә.

**Программаның максаты** - чын халык традицияләрен саклап калу һәм раслауга ярдәм итү, аларга хәзерге буын өчен үтемлелек тәэмин итү; халык-җыр сәнгате чаралары белән музыкаль-эстетик белем бирү, традицион халык бәйрәмнәре белән таныштыру..

**Бурычлары**:

Укыту:

1. Балаларны фольклор-этнографик материалда халык мәдәниятенең төрле формалары белән таныштыру.
2. Халык җырын аның төп иҗади һәм башкару закончалыкларын өйрәнү һәм үзләштерү.
3. Балаларга халык зирәклеге, матурлык һәм тормыш көче чыганагы буларак фольклор турында башлангыч күзаллаулар бирергә;

Развивающие:

1. фольклор чаралары белән балаларда артистик, эмоциональ сыйфатларны үстерү
2. Халык манерасында вокал - хор башкару күнекмәләрен алу..

Тәрбияви:

1. Төрле халыкларның сәнгатенә карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү.
2. Коммуникатив күнекмәләр формалаштыру һәм үстерү.
3. Яңа материал-ны үзләштерү; Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү уку эшчәнлеген оештыра белү.

4. Керәшен халкының да, башка халыкларның да мәдәни традицияләренә сак караш тәрбияләү;

Программа өч елга, 7-14 яшьлек балалар өчен исәпләнгән. Елына 132 сәгать, атнага 4әр сәгать.

Программа сәнгать юнәлешенә ия һәм түбәндәге документлар нигезендә төзелгән:

- - «Россия Федерациясендә мәгариф турында»2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы. •
- - РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының «башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә кертү һәм раслау турында»2009 елның 6 октябрендәге 373 номерлы боерыгы.
- «Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә керткәндә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру турында»Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү департаментының 2011 елның 12 маендагы 03-296 номерлы хаты
- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү буенча методик рекомендацияләр (11.06.2002 ел, № 30-15-433/16).
- «Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру турында»Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 14 декабрендәге хаты.
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясен раслаучы 2014 елның 4 сентябрендәге 1726-р номерлы күрсәтмәсе;
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы күрсәтмәсе " 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә Тәрбия үсеше стратегиясе»;
- «2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләү үсеше стратегиясен раслау турында»2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары; •
- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «мәгълүмат җибәрү турында "2015 елның 18 ноябрендәге 09-3242 номерлы хаты («гомуми үсештәге өстәмә

**Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм аларны тикшерү ысуллары:**

- фольклор жанрларының төрлелеге, кайбер халык йолалары һәм бәйрәмнәре: урак, кышкы һәм язгы, Масленица, язны каршылау турында күзаллауларга ия булу;

- татар һәм керәшеннәрнең костюмы һәм баш киемнәре турында белергә,

- керәшен,татар гореф-гадәтләре, хореография турында гомуми күзаллауга ия булу;

- эмоционально тапшырырга уен образлары;

- сәхнәдә иркен хәрәкәт итәргә;

- көйне дөрес көйләү;

**Программаны тормышка ашыруга йомгак ясау формалары:**

- укучыларның иҗади эшләре;

- төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашу;

- гамәли эшләр;

- конкурс-уен программасы;

**Беренче уку елына тематик план**

| № п/п | Темалар | Сәгатъ саны | | | Аттестация формалары/ контроль |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш.Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре.”Халык авыз иҗаты” турында белешмә. | 4 | 2 | 2 | әңгәмә |
| 2 | Борынгы бабаларыбызның ышанулары. | 10 | 4 | 6 | күзәтү, тест |
| 3 | Тел-шигъри фольклоры. | 18 | 4 | 14 | контроль сораштыру |
| 4 | Халык уеннары. | 32 | 6 | 26 | конкурс |
| 5 | Художестволы-гамәли эшчәнлек. | 30 | 10 | 20 | әңгәмә. |
| 6 | Гомуми этнографик мәгълүматлар. | 18 | 4 | 14 | конкурс, |
| 7 | Йолалар һәм бәйрәмнәр. | 18 | 4 | 14 | сораштыру |
| 8 | Йомгаклау. | 2 | | | әңгәмә |
| | Итого: | 132 | 34 | 98 | |

**Уку планының эчтәлеге**

**1 бүлек.** Кереш.Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре.

“Халык авыз иҗаты” турында белешмә. **-4с**.

**Теория.** Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, “Халык авыз иҗаты” турында әңгәмә уздыру.

**Практика**. Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча имза куйдыру. Дәфтәрдә эш.

**2 бүлек.** Борынгы бабаларыбызның ышанулары.**-10сәг**.

**Теория**.Әңгәмә.Сорауларга җавап алу.

**Практика.**Төрле ышанулар турында туплау. Альбом булдыру .Өйләрдә булу.

**3 бүлек.** Тел-шигъри фольклоры**.- 18 сәг**.

**Теория.**Әңгәмә.

**Практика.**Белешмәләр белән эш.Өйләрдә булу. Тест.

**4 бүлек.** Халык уеннары.-**32 сәг**.

**Теория.** Әңгәмә.Сорауларга җавап алу.Аңлату.

**Практика.**Сценарий төзү.

**5 бүлек.** Художестволы-гамәли эшчәнлек.-**30сәг.**

**Теория.** Әңгәмә.

**Практика.** Концертларда чыгыш ясау.

**6 бүлек.** Гомуми этнографик мәгълүматлар. – **18 сәг**.

**Теория.** Керәшеннәрнең яшәү урыны, рәвеше турында әңгәмә.

**Практика.**Өйләрдә булу, җырлар, нәселләре турында язып алу.

**7 бүлек.** Керәшен бәйрәмнәре.**- 18 сәг.**

**Теория.** Йолалар һәм бәйрәмнәр турында әңгәмә, китаплар белән эш.

**Практика.** Бәйрәмнәр турында сценарийлар язып, өйрәнү, чыгышлар ясау.

**8 бүлек.** Йомгаклау.

**Икенче уку елына тематик план**

| № п/п | Темалар | Сәгатъ саны | | | Аттестация формалары/ контроль |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш.Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре.”Халык авыз иҗаты” турында белешмә. Искә төшерү. | 4 | 2 | 2 | әңгәмә |
| 2 | Халык авыз иҗаты төркемнәре | 20 | 16 | 4 | күзәтү, тест |
| 3 | Керәшеннәр турында белешмә | 4 | 2 | 2 | контроль сораштыру |
| 4 | Йола һәм уен җырлары | 32 | 6 | 26 | конкурс |
| 5 | Туган төбәгебезнең милли бәйрәмнәре һәм өмәләре | 26 | 6 | 20 | әңгәмә. |
| 6 | Керәшен халык биюе хәрәкәтләре, җырлы биюле уеннар | 32 | 8 | 24 | конкурс, |
| 7 | Тирә-як өлкән буын кешеләре белән очрашу,танышу | 12 | 4 | 8 | сораштыру |
| 8 | Йомгаклау. | 2 | 2 | | әңгәмә |
| | Итого: | 132 | 44 | 88 | |

## Уку планының эчтәлеге

**1 бүлек.** .”Халык авыз иҗаты” турында белешмә.**- 4с.**

**Теория.** Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, фольклор турында искә төшерү.

**Практика.** Багу поэзиясе, күңел ачу , фольклоры буенча практик дәрес.Җырлар, юраулар җыю.

**2 бүлек.**Халык авыз иҗаты төркемнәре **-20әг.**

**Теория**. Табышмаклар .Әкиятләр **.**Мәзәкләр**.** Тизәйткечләр**.** Мәкаль-әйтемнәр, уен җырлары,мифлар, бәетләр турында сөйләшү.Эчтәлекләрен анализлау

**Практика**. Дәфтәр булдыру. Мәзәкләр, табышмаклар, әкиятләр **,** тизәйткечләр җыю. Конкурс, кичә уздыру.

**3 бүлек.** Керәшеннәр турында белешмә. **- 4сәг.**

**Теория.** Авылыбыз тарихы, авылыбыз алдынгылары,керәшеннәр арасыннан чыккан билгеле шәхесләр турында барлау.

**Практика**.Өйләрдә булу, альбом ясау.Очрашулар уздыру. Йолалар үтәү. Кием салымнар һәм бизәнү әйберләре җыю.

**4 бүлек.** Йола һәм уен җырлары. **- 32сәг.**

**Теория**. Җырлар, такмаклар турында сөйләшү. язып алу,коен өйрәнү.

**Практика**.Ел фасылы белән бәйле җырлар.Туй йоласына караган җырлар.Уен җырлары.Бию такмаклары язып алу,коен өйрәнү, чыгышлар ясау, туплау.

**5 бүлек.**Туган төбәгебезнең милли бәйрәмнәре һәм өмәләре. **- 26 сәг.**

**Теория.** Йолалар, керәшен бәйрәмнәре турында аңлату, яздыру.

**Практика** .Ел фасыллары белән бәйле йолалар.Бәйрәмнәр.Туй йолалары турында белешмәләрдән карау. Өйләрдә булу. Алар турында сорау.Тестлар уздыру.

**6 бүлек.** Керәшен халык биюе хәрәкәтләре, җырлы биюле уеннар - **32 сәг.**

**Теория** .Керәшен җырлары, биюләре турында әңгәмә .

**Практика**.Өйләрлә булу, җырлар язып алу. Аларны өйрәнү,музейга эшләрен җыю.

**7 бүлек.** Тирә-як өлкән буын кешеләре белән очрашу,танышу. **12сәг.**

**Теория.** Өлкән буын кешеләрен барлау.

**Практика**. Алар белән очрашу, өйләрендә булу**.**

**8 бүлек.** Йомгаклау.**2сәг.**

**Өченче уку елына тематик план**

| № п/п | Название раздела, темы | Количество часов | | | Формы аттестации/ |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Всего | Теория | Практика | |

| | | | | | контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш.Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре. .”Халык авыз иҗаты”турында белешмә. Искә төшерү. | 4 | 2 | 2 | әңгәмә |
| 2 | Халык авыз иҗаты төркемнәре | 22 | 18 | 4 | күзәтү, тест |
| 3 | Күренекле якташларыбыз турында белешмә | 10 | 6 | 4 | контроль сораштыру |
| 4 | Йола һәм уен җырлары | 28 | 12 | 16 | конкурс |
| 5 | Туган төбәгебезнең милли бәйрәмнәре . | 26 | 6 | 20 | әңгәмә. |
| 6 | Дини бәйрәмнәр, җырлы-биюле уеннар. | 32 | 10 | 22 | Сораштыру,конкурс |
| 7 | Әбиемнән өйрәнәм. | 8 | 4 | 4 | әңгәмә |
| 8 | Йомгаклау. | 2 | | | әңгәмә |
| | Итого: | 132 | 44 | 88 | |

**Уку планының эчтәлеге**

**1 бүлек.** Кереш.Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре. .”Халык авыз иҗаты” турында белешмә. Искә төшерү.- **4с.**

**Теория.** Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, .”Халык авыз иҗаты” турында искә төшерү.

**Практика.** Багу поэзиясе, күңел ачу , фольклоры буенча практик дәрес.Җырлар, юраулар җыю.

**2 бүлек.**Халык авыз иҗаты төркемнәре -2**2сәг.**

**Теория**. Табышмаклар .Әкиятләр **.**Мәзәкләр**.** Тизәйткечләр**.** Мәкаль-әйтемнәр,бәетләр турында сөйләшү.Эчтәлекләрен анализлау

**Практика**. Дәфтәр булдыру. Мәзәкләр, табышмаклар, әкиятләр **,** тизәйткечләр,бәетләр җыю.Конкурс, кичә уздыру.

**3 бүлек.** Күренекле якташларыбыз турында белешмә. **- 10сәг.**

**Теория.** Авылыбыз тарихы, авылыбыз алдынгылары,якташлар арасыннан чыккан билгеле шәхесләр турында барлау.

**Практика**.Өйләрдә булу, альбом ясау.Очрашулар уздыру. Йолалар үтәү. Кием салымнар һәм бизәнү әйберләре җыю.

**4 бүлек.** Йола һәм уен җырлары. **- 28сәг.**

**Теория**. Җырлар, такмаклар турында сөйләшү. язып алу,коен өйрәнү.

**Практика**.Ел фасылы белән бәйле җырлар.Туй йоласына караган җырлар.Уен җырлары.Бию такмаклары язып алу,коен өйрәнү, чыгышлар ясау, туплау.

**5 бүлек.**Туган төбәгебезнең милли бәйрәмнәре. **- 26 сәг.**

**Теория.** Йолалар, бәйрәмнәр турында аңлату, яздыру.

**Практика** .Ел фасыллары белән бәйле йолалар.Бәйрәмнәр.Туй йолалары турында белешмәләрдән карау. Өйләрдә булу. Алар турында сорау.Тестлар уздыру.

**6 бүлек.** Дини бәйрәмнәр, җырлы- биюле уеннар **32сәг.**

**Теория** .Дини бәйрәмнәрне барлау.

**Практика**.Өйләрлә булу, музейга эшләрен җыю..Мастер класс уздыру.

**7 бүлек.** Әбиемнән өйрәнәм. -**10сәг.**

**Теория** .”Минем әбием бик оста”- әңгәмә,

**Практика**.Өйләрлә булу, музейга эшләрен җыю. Аларны очрашуга чакыру.Сочинение язу.

**8 бүлек.** Йомгаклау.-**2сәг.**

**Түгәрәкне методик яктан тәэмин итү.**

“Халык авыз иҗаты” программасын методик яктан тәэмин итүгә дидактик принциплар, методлар, техник җиһазлау, оештыру эшләре, нәтиҗә чыгару формалары

керә. Занятиеләргә әзерләнгәндә, укыту процессын оештыру нормаларына һәм дидактик принципларга аерым игътибар бирелә.
Иң беренче чиратта - күрсәтмәлелек принцибы. Уку-укыту процессында, куелган максатка ирешү өчен, системалылык һәм эзлеклелек зур роль уйный. Шулар аша укучылар әкренләп белем һәм күнекмәләргә ия булалар. Педагог уку-укыту планын системалылык һәм эзлеклелек принципларына нигезләнеп, үзгәртү мөмкинлеген дә күздә тотып төзи. Иҗат эшчәнлегенең иң кирәклесе булган мөстәкыйльлеккә дә зур игътибар бирелә. Аның аша теорияне практика белән бәйләү, ныклы белем һәм күнекмәләргә ия булырга мөмкин.

**Дидактик, методик һәм гамәли** яктан дөрес оештырылган түгәрәк эше укучыларның белемнәрен киңәйтә, иҗади сәләтләрен үстерүгә ярдәм итә. Түгәрәкнең педагогик яктан эффектлылыгы тагын шунда: укучылар дәрестә булмаган кызыклы материал белән танышалар. Дәрестән тыш чараларда катнашу нәтиҗәсендә алган белемнәрен дәрестәге мөстәкыйль эш вакытында да файдалана алалар.

Түгәрәк эшчәнлегендә кулланылган методлар, программаны тормышка ашыруда аеруча әһәмияткә ия.

1.Аңлату. Укытучы күрсәтмә әсбаплардан (таблица, схема, рәсем), интернет чыганаклардан, үзенең үрнәк эшләреннән файдаланып, төрле мисаллар өстендә өйрәнә торган материалны укучыларга аңлата, шул ук вакытта укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыруны да күздә тота

2. Әңгәмә. Укучыларның танып белү эшчәнлекләрен активлаштырырга, уйлау сәләтен үстерергә, түгәрәктәге барлык укучыны да эшләтергә ярдәм итә.

3.Алган белемнәрне файдаланып, эшләгән эшне тикшерү, бәя бирү.

4.Очрашулар. Авылыбызның алдынгы кешеләре белән, әти-әниләр белән очрашулар үткәрү.

**Эш принциплары:**

- системалылык,
- мөстәкыйльлек – иҗат эшчәнлегенең иң кирәклесе;
- гуманлылык.

**Матди- техник җиһазлау**

- дәрес уздыру өчен кабинет булу;
- темаларга кагылышлы китаплар булу;
- презентация әзерләү һәм карау өчен мөмкинлек булу;
- интернетка чыга алу.

**Аттестация һәм контроль формалары**

- иҗади эшләр
- диагностика, -
музыкаль сораштыру
җирле җырлар, хикәяләр һ. б. җыю
- ачык дәресләр үткәрүдә катнашу
- конкурсларда катнаш

**<u>Файдаланылган әдәбият исемлеге:</u>**

1.Алдошина Л. И. Проведение фольклорных праздников в школе.

Педагогическое общество России. - М., 2005.- 128 с.

2.Балалар фольклоры. Казан . 2008

3.Бәетләр, мөнәҗәтләр. Казан :”Мәгариф” нәшрияты,2005

4.Без бер тамырдан.Казан :”Мәгариф” нәшрияты,2002.

5.Йола һәм уен җырлары. Казан.Татарстан китап нәшрияты, 2007.

6.Керәшен бәйрәмнәре. Сценарийлар.2010.

7.Татар халык иҗаты. Табышмаклар. Казан :”Мәгариф” нәшрияты,2002.

8.Энҗе чәчтем-энҗе җыям.Татар халык уеннары. . Казан :”Мәгариф” нәшрияты,2005